Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Балтач районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Балтач районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 122-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
Балтач районы буенча
Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Карадуган, Кече Лызи, Норма, Сасна һәм Шубан авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Балтач муниципаль районының Борбаш, Борнак, Югары Субаш, Куныр, Нөнәгәр, Пыжмара, Салавыч, Смәил, Урта Көшкәт, Чепья, Шеңшеңәр һәм Яңгул авыл җирлекләре.